Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № № XIII-9**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 16 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 30 июнендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законга, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 сентябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 22 июль 2013 ел XXVII-6, 14 август 2014 ел XXXIX-3, 13 декабрь 2014 ел XLII-8, 14 ноябрь 2015 ел V-3, 23 апрель 2016 ел X-8 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 маддәне яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре.

2.6.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, белем һәм күнекмәләр буенча эш стажына карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә, алар вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәк, шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булганда – белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата.

2.6.2. Һөнәри белем бирү дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре әлеге Нигезләмә белән муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 маддәсендәге 3 өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү

өчен типовой (үрнәк, бер типҗагы) квалификация таләпләре нигезендә билгеләнә. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

2.6.3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы кимендә ике ел яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы кимендә бер ел яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

2.6.4. Өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

2.6.5. Әлеге маддә максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте Вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт Вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларында башка төр хезмәт стажы исәпкә алына.

2.6.6. Контракт буенча билгеләнә торган муниципаль районның җирле администрациясе башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр белән кимендә биш ел идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе булу билгеләнә. Әлеге пунктта идарә эшчәнлеге дигәндә оешма җитәкчесе, җитәкче урынбасары, дәүләт органы, муниципаль орган вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең вазыйфаларындагы эш аңлашыла.

2.6.7. 2018 елның 1 гыйнварына кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (сәркатибе) вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем бирүне күздә тота дип билгеләргә.

2.6.8. 2019 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре (урта гомуми белем булган очракта) түбәндәге шарт булганда күрсәтелми дип билгеләргә: муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларга «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге

33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу керә.»;

2) 6.1 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1) әлеге Нигезләмәнең 9.1 бүлегендә каралган мәгълүматлар тапшырмау;»;

3) түбәндәге эчтәлекле 9.1 бүлек өстәргә:

«9.1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында мәгълүматлар тапшыру

9.1.1«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр һәркем файдалана алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирүче күрсәткечләрне урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматларны яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыралар:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, - хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәткә керү елыннан алдагы өч календарь ел өчен;

2) муниципаль хезмәткәр - күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен ел саен, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны урнаштыру очраклары керми.

9.1.2. Әлеге бүлекнең 9.1.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар муниципаль хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырыла, ә муниципаль хезмәткәр тарафыннан - хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча. Әлеге бүлекнең 9.1.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рәвештә тапшырыла.

9.1.3. Эшкә алучының вәкиле карары буенча, вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган һәркем файдалана алырлык мәгълүматны эшкәртә, шулай ук әлеге бүлекнең 9.1.1 пунктында каралган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү.»;

4) 10.1 маддәнең 10.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:

«10.1) әлеге Нигезләмәнең 9.[1] бүлегендә каралган мәгълүматлар;»;

5) 11.2 маддәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белгечлек, әзерлек юнәлеше, белем һәм күнекмәләр буенча эш стажына карата квалификация таләпләре, шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата - яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасын биләү өчен белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү турында карары булганда;»;

6) Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең аттестациясен үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 3

пунктына «белгечлек» сүзеннән соң «, әзерлек юнәлеше » сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев